СОВЕТ ОСИНОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОСИНОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**«28» ноябрь 2024 ел** с.Осиново **№ 184**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Осиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә туристлык салымын кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 33.1 бүлегенә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Осиновское сельское поселение» муниципаль берәмлеге Уставына, Зеленодольск муниципаль районының Осиново авыл җирлеге советына ярашлы рәвештә карар кылдым:

1. 2025 елның 1 гыйнварыннан Зеленодольск муниципаль районының «Осиновоское сельское поселение» муниципаль берәмлеге территориясендә туристик салым кертергә.

2. Туристлык салымы ставкасын түбәндәгечә билгеләргә:

- 2025 елда салым базасының 1 проценты күләмендә,
- 2026 елда салым базасының 2 проценты күләмендә,
- 2027 елда салым базасының 3 проценты күләмендә
- 2028 елда салым базасының 4 проценты күләмендә
- 2029 елдан башлап салым базасының 5 проценты күләмендә.

3. Әлеге карар, рәсми басылып чыккан көненнән 1 айдан да иртәрәк булмаган вакытта, 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат Порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Осиново авыл җирлеге башлыгы Ю.А.Харинкин